ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
БИЕКТАУ
ВЫСОКОГОРСКОГО
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ
422700, Татарстан Республикасы, Биектау районы,
Биектау тиемер юл станциясе поселогы, Совет урамы, 13

СОВЕТ КРАСНОСЕЛЬСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
ВЫСОКОГОРСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
422700, Республика Татарстан, Высокогорский район,
п. ж/д. ст. Высокая Гора, ул. Советская, 13

тел./факс 8(84365) 2-35-82, e-mail: Ksel.Vsg@tatar.ru

**КАРАР** | **РЕШЕНИЕ**

**26 октябрь 2022 ел** | **№ 55**

# Красносельский авыл җирлеге Советының 2018 нче елның 4 нче маендагы 85 нче номерлы «Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Красносельский авыл җирлеге җирле үзидарә органнарының муниципаль хезмәткәрләренең даими нигездә үз вәкаләтләрен гамәлгә ашыручы җирле үзидарәнең сайланулы вазыйфаи затларына, депутатларга хезмәт өчен түләү чыгымнарын формалаштыру нормативлары турында» гы карарына үзгәрешләр кертү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 нче елның 6 нчы октябрендәге 131-ФЗ номерлы Россия Федерациясе Федераль законы нигезендә, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2022 нче елның 22 нче августындагы 881 нче номерлы «Муниципаль берәмлекләр башлыкларының, муниципаль берәмлекләр башлыклары урынбасарларының, депутатларның, җирле үзидарәнең даими нигездә үз вәкаләтләрен гамәлгә ашыручы сайланулы органнары әгъзаларының, муниципаль берәмлекләрнең контроль-хисап органнары рәисләренең, рәис урынбасарларының, аудиторларының һәм Татарстан Республикасында муниципаль хезмәткәрләрнең вазыйфаи окладларының айлык акчалата түләү күләмнәрен арттыру турында» карары белән, Красносельский авыл җирлеге Уставы белән, Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Красносельский авыл җирлеге Советы,

## КАРАР КЫЛДЫ:

1. Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Красносельский авыл җирлеге Советының 2018 нче елның 85 нче номерлы «Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Красносельский авыл җирлеге җирле үзидарә органнарының муниципаль хезмәткәрләре, үз вәкаләтләрен даими нигездә гамәлгә ашыручы җирле үзидарәнең сайланулы вазыйфаи затларына депутатларга, сайланулы вазыйфаи затларга хезмәт өчен түләү чыгымнарын формалаштыру нормативлары турында» гы карары белән расланган, Биектау муниципаль районы Красносельский авыл җирлеге башлыгы урынбасарының ай саен акчалата бүләкләү күләмен 2022 нче елның 1 нче октябреннән 1,04 тапкырга арттырырга. (2018 нче елның 24 нче сентябрендәге 96 нчы номерлы, 2020 нче елның 23 нче октябрендәге 4 нче номерлы Совет карары редакциясендә).

2. Красносельский авыл җирлеге Советының 2018 нче елның 4 нче маендагы

85 нче номерлы карары белән билгеләнгән тәртиптә билгеләнә торган, Биектау муниципаль районының Красносельский авыл җирлегендә муниципаль хезмәткәрләрнең вазифа окладлары күләмен 2022 нче елның 1 нче октябреннән муниципаль хезмәт вазыйфаларына туры китереп арттырырга, «Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Красносельский авыл җирлеге җирле үзидарә органнарының муниципаль хезмәткәрләре, үз вәкаләтләрен даими нигездә гамәлгә ашыручы җирле үзидарәнең сайланулы вазыйфаи затларына депутатларга, сайланулы вазыйфаи затларга хезмәт өчен түләү чыгымнарын формалаштыру нормативлары турында» (2018 нче елның 24 нче сентябрендәге 96 нчы номерлы, 2020 нче елның 23 нче октябрендәге 4 нче номерлы Совет карары редакциясендә).

3. Әлеге Карар нигезендә муниципаль хезмәткәрләрнең вазыйфаи окладларының күләмнәрен исәпләп чыгару өчен авыл җирлегендә муниципаль хезмәт вазыйфаларының кече төркеме белгеченең вазыйфаи оклады күләмен 1,04 мәртәбә индексацияләргә һәм аны 13274 күләмендә билгеләргә.

4. Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Красносельский авыл җирлеге Советының 2018 нче елның 4 нче маендагы 85 нче номерлы карары белән расланган 2 нче кушымта «Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Красносельский авыл җирлеге җирле үзидарә органнарының муниципаль хезмәткәрләре, үз вәкаләтләрен даими нигездә гамәлгә ашыручы җирле үзидарәнең сайланулы вазыйфаи затларына депутатларга, сайланулы вазыйфаи затларга хезмәт өчен түләү чыгымнарын формалаштыру нормативлары турында» (2018 нче елның 24 нче сентябрендәге 96 нчы номерлы, 2020 нче елның 23 нче октябрендәге 4 нче номерлы Совет карары редакциясендә), таблицаны түбәндәге редакциядә бәян итегез:

«Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Красносельский авыл җирлеге башлыгы урынбасары акчалата бүләкләү күләме»

| Вазыйфаның исеме | Акчалата бүләк күләме (сумнарда) |
|---|---|
| | 10 нчы төркем |
| Авыл җирлеге башлыгы урынбасары | 14527 |

5. Әлеге карарны гамәлгә ашыруга бәйле чыгымнарны финанс белән тәэмин итү тиешле финанс елына Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районының Красносельский авыл җирлеге бюджетында каралган бюджет ассигнованиеләре чикләрендә гамәлгә ашырыла дип билгеләргә.

6. Әлеге карарны авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында, Биектау муниципаль районының рәсми сайтында http://vysokaya-gora.tatarstan.ru/ авыл җирлекләре бүлегендә һәм Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматның рәсми порталында http://pravo.tatarstan.ru/ урнаштыру юлы белән бастырып чыгарырга (халыкка җиткерергә)

7. Әлеге карар 2022 елның 1 октябреннән рәсми басылып (халыкка җиткерелгәннән) соң үз көченә керә.

8. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үз өстемдә калдырам.

Совет Рәисе,
Авыл җирлеге Башлыгы Р. Ф. Хисаметдинов